

Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә яшәгән Исмәгыйль Шәнгәрәевне белмәгән кеше юктыр, ә менә анын тормыш иптәше МәрьямШәнгәрәева – кvпләргә ачылмаган сер булып кала. Әйдәгез, бергәләп якыннан танышыйк әле 11 бала әнисе, 10 оныk әбисе белән... – Хәерле көн, Мәряьм апа! Үзегез белән таныштырып китегез әле. Чыгышыгыз кайдан? Ничек итеп көн кvреп ятасыз? – Хәерле кон! Чыгышым белән мин Үзбәкестаннан, шунда туып 17 ел яшәдем. Әтием – Шахмамедов Әнвәр, Үзбәкстан кешесе, әнием – Шахмамедова Фирдәvсә, Казаннан.Гаиләдә алты бала vстек.Киявгә чыктым 17 яшьтә. Әти-әнием 1997 елдан бирле Казанда, Мирный бистәсендә яшиләр.

– Рәшидә абыстай оныгы булуы авырмы?

– Юк авыр тvгел, кvнеллерәктер. Мин анын беренче кызы Фирдәvеснен беренче кызы булам инде. Минем дәv әниемнен алты баласы булган: Фирдәvес, Рабига апа, Рәмзия апа, Исламия апа, Рушания апа, Госман хәзрәт. Әбием биш кыз һәм бер малай vстергән. Ул елга бер мәртәбә кунакка килә иде Үзбәкстанга. Безгә килгәч, гел vзенен vгет-нәсихәтләрен калдырып китә иде безгә:

– Намазлы булыгыз һәм икенче кvрешкәндә менә шушы догаларны яттан белегез, – дип биремнәр калдырып китер иде. Сонынnан имтихан алыр иде дә Машалла, дип әйтер иде. Киләсе очрашуга кабат бирем калдырып китә иде...

– Ирегез белән кайда, ничек таныштыгыз?

– Ирем белән Казанда туганнар таныштырды. Үзбәкстанда мәктәпне тәмамлагач,1991 елда, Казан дәvләт педагогика институтына инглиз-гарәп телләре бvлегенә укырга керергә, дип килдем. Ботен документларымны тапшырдым да Богелмә шәһәрендәгеапаларга куннаккакиттем. Аннан Богелмәдәге әниемнен сенлесе –Рабига абыстай һәм ире – Соләйман хәзрәт белән Оренбург оязе Богырыслан шәһәрендәге туганнарга кунакка юл тоттык. Шунда Исмәгыйль абыен белән таныштырдылар.Бер айдан сон индекиявгә чыктым. Исмәгыйлькунаклар очен туйгабер самолет яллап алды. Шул самолетта Богырыслан, Ульян, Самара, Мәскәv, Татарстан, Башкортостан якларыннан кунаклар ботенесе туй мәжлесенә Самарадан Ташкентка очтылар. Горләтеп Чирчик шәһәрендә 500 кешелек туй уздырдык. Никахны Соләйман һәм Госман хәзрәтләр укыды.Шундый онытылмас мизгелләрдән сон, мин Шәнгәрәева булдым. Ун ел Богырыслан шәһәрендә яшәдек, шуннан сон Мәскәvдә тормыш иттек, хәзер инде 2006 нчы елдан бирле Берләшкән гарәп Әмирлекләрендә яшибез.

– Әниләреннән ятим булып калган балаларны якын итеп кабул иткәнсез. Үз балаларыгыз тугач, тәрбия өлкәсендә каршылыклар булмадымы?

– Тәрбия олкәсендә каршылыклар булмады. Исмәгыйльнен олы апасы – Рәйсә алдан ук жайлап, балалар белән vтемле итеп сойләшкән, анлаткан: “Әниегез мәрхvмә, шуна кvрә әтиегез икенче әни ала сезгә”, – дип.Аллага шокер, шуннан бирле “әни” дип йорттеләр. Әлхәмдулилләх, ирем дә ботен тормышны берсулышта, яхшы итеп алып барды, балаларга да, мина да авырлык тошмәде. Бер баланы икенчесеннән аерырга вакыт табулмады, килем-китем(кунак) мәшакате кvп булды. Андый вак-тояк проблемалар булмады, шокер.

– Бала тәрбияләvдә сез нәрсәгә өстенлек бирәсез?

– Әлбәттә, дини тәрбиягә остенлекбирелә. Балаларны шәригать кануннары буенча тәрбиялибез.

– Балаларыгыз ничә яшьтән намаз укый башлый?

– Анлый башлагач. Ә болай 2-3 яшьтән vзләре басалар намазга. Kvреп vсә бит ул аны.

– Kvpvемчә, монда гарәп хатын-кызлары ашыкмыйлар, алар салмак, жайлап кына яшәvгә kvнеккән, шикелле. Бу нәрсә белән бәйле?

– Дини тормыш белән. Без андый тормышка ойрәнәбез, ә аларнын балачактан ук гадәтләренә кергән инде андый тормыш. Шуна кvрә алар ашыкмыйлар, дулкынланмыйлар, чонки иманнары нык, ботен эшне Ходайга тапшыралар, язмыш алдан язылган, дип кенә карыйлар. Рәсәйдәге халык эшләренен унышлы булуы алардан гына, аларнын тиз эшләvләреннән генә тора дип фикер йортәләр, шуна кvрә ашыгалар,кабаланалар... Ә мондагы халык эшен Ходайга тапшыра... житешмәсәләр дә исләре китми. Ходайдан шулай хәерлерәктер, дип тыныч кына уйлап куялар. Аларнын да бардыр инде авырлыклары, безгә генә бер проблемасыз, ашыкмыйча йориләр кебек тоеладыр... Тыштан гына кvренми безнен мәшәкать аларга, аларныкы безгә. Тормышта бар нәрсәгә kvнегәсен, kvнегергә кирәк тә.

– Барлык баларыгыз бер-берсен хөрмәт итәләр... олысын – олы итеп, кечесен –кече итеп kvрәләр, тәvфыйклы вә иманлы балалар булып vссеннәр өчен, нинди тәрбия алымнары кулландыгыз?Ишле гаиләне бердәм итептуплау өчен нишләргә кирәк?

– Беренчедән, балалар очен син vзен vрнәк булырга тиеш.Ата-ана ойдә нинди – балар шуны сендереп vсә һәм киләчәктә сине кабатлый. Тикмәгә генә “Бала оясында ни kvрсә, очканда шуны kvрсәтер” дигән мәкаль яшәми халыкта. Икенчедән, ойрәтәсен инде бусы–абыен синен дип, монысы апан, энен, сенлен, дисен. Һәрвакыт ойрәттек ирем

белән балалар бер-берсенә абыем-апам, энем-сенлем дип дәшсеннәргә. Моһим тvгел: бер елга олыракмыяисә бер айгамы, я бер генә конгәме. Барыбер ойрәтәбез бу синен абыен, аны хормәт итәргә, тынларга, ана кашы дәшмәскә, кычкырмаска, олкәннәр белән талашмаска кирәк дип. Бу татарда олкәннәргә хормәт йозеннән эшләнелә торган язылмаган канун дип әйтәсем килә.

– Менә карап торам: тынламасан хәзер абыен белән апана әйтәм дисез, балалар куркалар һәм шунда ук рәткә киләләр бер шул гади cvздән. Нәрсә белән бәйле бу?

– Белмим. Kvрәсен, бер-берсе белән кvбрәк аралашалар, сойләшәләр һәм vтемле итеп анлаталардыр яшьләр(колә). Әмма әйткәлим шулай – монысы хак.

– Ирегез тәрбия эшендә ни рәвешле катнаша?

– Тәрбия әти ягыннан бик нык бара. Kvп нечкәлекләрне тәрбия олкәсендә мин иремнән ойрәндем. Эштә булганда шалтыратып сораша: балалар нәрсә әшли, нәрсә белән шогельләнәләр, татарча сойләшәләрме, дип кvздән ычкынрмый. Олы балалар белән – олыларча, сабыйлар белән – сабый телендә әнгәмә кора. Рәхәтләнеп кечкенә балалар белән уйнап та утыра әле. Анын vз ысуллары. Мәсәлән, жомга конне, барыбыз жыелгач, ул безгә әдәп,әхлак дәресләре бирә: ничек сойләшергә, кешеләр алдында vзенне ничек тотарга, ничек тормыш алып барырга.

– Балаларыгыз нинди мәктәптә укыдылар, укыйлар? Нинди югары уку йортларын тәмамладылар? Тел белән кыенлыклар тумыймы?

– Хәдия, Жәлил, Мохәммәд, Кәvсәрия чит ил мәктәпләрен, Ислам белән Мослимә Мәскәv мәктәбен тәмамладылар. Ә башкалары vзебезнен янда Расельхайм әмирлегендә урнашкан мәктәптәукыйлар әле.

– Кызлардан кала ботен улларым очен югары уку йорты ул – әтиләре инде, әтисенен эшләре. Олы кызым читтән торып, Мәскәv университетын тәмамлады, экономист. Ә кечесе Шарджа әмирлегендә менеджмент юнәлешен сайлады, әлегә шунда укый.

– Балаларыгыз ничә тел белә?

– Дvрт тел беләләр: татар, рус, инглиз, гарәп телләрен.

– Алар өчен татар теле нәрсәгә кирәк дип уйлыйсыз?

– Yзен хормәт иткән һәр кеше ана телен белергә тиеш. Татар теле– ана теле ул.Шуна

kvрә алар телебезне, буыннан буынга килгән гореф- гадәтләребезне, йолаларны белергә тиеш. Мин – милләт анасы! Шуна kvрә жәмгыятькә, татар халкыма тугры, динле, нык иманлы, дәvләтебезгә файда китерә торган тәvфыйклы балалар vстерергә тырышабыз. Милләтне телсез саклап калып булмый. Шуна kvрә татар телен онытмыйк, дуслар!

– Кием мәсьәләсенә килгәндә, сезгә нинди стиль якынрак: гарәп стилеме, яисә татарныкымы?

– Икесе дә якын. Элек-электән ин моһиме хатын-кызнын гәvдәсе капланган булырга тиеш. Библиядә дә әйтелгән бу хакта, коръәндә бигрәк тә. Гарәп илендә урамда артык kvзгә бәрелмәс очен кара kvлмәк киям. Ә инде Рәсәйдә мин татарларыбызга хас тыныч-якты тостәге kvлмәк киергә тырышам. Аерма шунда гына.

– Балаларыгыз vсеп беткәч,аларнын читкә китvләренә, яшәvләренә ничек карыйсыз? Ничә балагыз аерым бер гаилә булып яши, кайда?

– Яхшы карыйм. Насыйп ярларын табып аерым тора башлыйлар икән –без шат кына.Оч балам тормыш корып, гаиләләре белән аерым яши. Кызым Мослимә ире һәм дvрт баласы беләнМәскәvдә яши. Ислам һәм Жәлил улларым гаиләләре белән Аджман әмирлегендә vз фатирларында торалар.

– Балага исем сайлаганда нәрсәгә игътибар итәсез?

– Чын моселман исеме булырга тиеш. Безнен балаларнын ботенесендә иске татар исемнәре, ә иске татар исемнәре алар барысы да коръәндә язылган. Балага нинди исем кушсан – тормышы шундый була. Безнен бурыч–балага мәгънәле исем бирv. Бездә балаларга исемнеминем белән кинәшләшеп, Исмәгыйл абыегыз сайлый.

– Мәрьям апа, ничек итеп инсафлы, анасына да, жәмгыятькә дә, киләчәк буыннарга да сөенеч китерә торган бала тәрбияләргә мөмкин?

– Ин беренче чиратта сабырлык кирәк. Баланы ачуланганда,ул vз хаталарын анламый да, анларга теләми дә. Чvгәләп, янына утырып, тыныч кына анлата белергә кирәк. Психология ягыннан карасан да, пәйгамбәребезнен соннәте буенча да баланы жиде яшькә кадәр ачуланырга, ана сугарга, кыйнарга, әрләргә ярамый. Коръәндәязылган бу хакта. Тиккә әйтмиләр бит: “Психология – развернутая книга ислама”, – дип. Бер конне балам Ибраһим әйтә: Әнкәй, син беләсенме, мелатонин гармонykешенен организмында кичке 21.00 сәгать 2.00 кадәрбарлыкка килә икән,дип. Бу нәрсәне анлата? Медицина белән дин бик нык бәйләнештә тора һәм алар арасында каршылыклар юк дигән cvз. Пәйгамбәребезнен соннәте бар: ястv намазын укыгач, ятып йокларга дигән. Kvпчелек белә, әмма дорес итеп vтәмибез. Ә шәригать кануннары буенча тәрбия барса,бу шартлар

ботенесе дә vтәлә: балан инсафлы да, анасына да, жәмгыятькә дә соенеч китерә торган була.

– Бvгенге көндә Татарстанда тел мәсъәләсе ата-ана ихтыярында калды. Татарстанда да кайбер татар гаиләләре ана телен кирәксенмичә, укытуда рус телен сайладылар. Бу хакта сезнен фикерегез нинди?

– Безнен балалар очен татар телендә мәгълvмат кабул итv авыррак, чонки балачактан ишетеп vсмиләр татар телен. Шуна кvрә башка фәннәр белән берьюлы татар телендә ойрәнсәләр яхшы булыр иде vзләренә. Әмма мәктәп дәресләре генә житми, гаиләдән башларга кирәк туган телне ойрәнvне. Үземне дә эти-әниләр ойдә татарча сойләшегез, дип vстерделәр. Без дә vзебезнен балаларга ойдә татарча сойләшегез дигән таләп куябыз.Ойдә татар телендә генә аралашканга кvрә, балаларыбыз ана телен онытмыйлар.

– Катнаш никахларга мөнәсәбәтегез нинди? Балаларыгызнын чит милләт кешесе белән гаилә коруына риза булыр идегезме?

– Тискәре.Мин мона каршы. Тормышынны vз милләт кешесе белән бәйләргә кирәк. Динебез Ислам нинди чиста, пакь, дорес дин бит!

Ислам динендә булса, кайбер очракларда ризалашыр идем дә, әмма киләчәгенне, якыннарынны кvздән кичереп, барысын да алдан уйлап эшләргә кирәк. Гаиләле балаларым әлегә ботенесе татар кешеләренә ойләнделәр, киявгә чыктылар. Иншаалла, алга таба да шулай булыр!

– Татарстандагы татарларга нинди теләктә калыр идегез?

– Балаларыгызны татарча сойләшергә ойрәтергә тырышыгыз. Якын булыгыз аларга.Эш артыннан гына кумыйча, ким дигәндә ике сәгать вакытыгызныбалага гына багышлагыз. Чонки берни дә эзсез калмый.Сонынnан vкенерлек булмасын!

Әнгәмәгез өчен рәхмәт!

Әнгәмәдәш – Алсу Жиһаншина,

Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Дубай

5.01.2019 ел

Перейти в фотоальбом